# Мәктәп хәбәрчесе

№2 (№53) февраль 2024 ел

Түбән Майна урта мәктәбе газите


Тел. 8 (84344) 4-38-46 sch1644maina@mail.ru





*/Мөхәррир минбәре/*

## *Ватанны сакларга әзерләнәбез*

Ватанны саклаучылар көне – батырлык, намус һәм Ватанга мәхәббәт бәйрәме ул. Бу көнне төрле яшьтәге ир-атларны бәйрәм белән котлыйбыз. Бүгенге көндә Туган илебезгә мәхәббәт тәрбияләү, аны саклау – мөһим мәсьәләләрнең берсе булып тора. Укучыларыбызны кече һәм олы Ватаннарына игътибарлы, туганнарына, якыннарына ныклы таяныч булып, тормышның барлык сынауларына, авырлыкларга бирешми торган егетләр итеп күрәсебез килә. Сездә көч-куәт, батырлык ташып торсын! Һәр көнегез – уңышлы, һәр гамәлегез — лаеклы, сәламәтлегегез — ныклы, һәр сүзегез — ышанычлы булсын!





Туган илгә һәм үз халкыңа хезмәт итү ул, туган илен чын күңелдән сөюче гражданнарның һәрчак иң югары максаты булды һәм шулай ук булып калса иде. Безнең мәктәбебездә дә бу көн ел саен шау-гөр килеп уздырыла. Бу елны да егетләр арасында ярыш уздырдык. Малайлар «Алга» һәм «Тимер» командаларына бүленеп физик көч, акыл, хәрби спорт төрләрендә буенча сынаштылар. «Алга» командасындагы егетләр җиңү яулап алды. Алар урамда карта белән билгеләнгән флагны да табып китерделәр. Бу безнең егетләрдән зирәклек, үткенлек таләп итә. Физик көчләре дә егетләрнең бу чарада ачыктан-ачык күренде. Ир-егетләрнең көче – горурлык, акылы –алтыннан кыйммәт хәзинә икәненә тагын бер кат ышандырырлык чара иде бу. Тормышта да югалып калмый торган, авырлыкларга бирешми торган егетләр булып җитешеп, авылыбыз, туган ягыбыз горурлыгы булырлар дип ышанып калыйк.

***"Мәктәп хәбәрчесе" редколлегиясе***

*/Мәктәп тормышы/*

## *Сау бул, Әлифба!*




Беренче сыйныф укучыларының тәүге җиңүе итеп хәрефләр иле булган Әлифба китабын укып тәгәлләүне атап була. 5 нче февраль көнне мәктәбебездә Әлифба белән саубуллашу бәйрәме булып үтте. Балалар үзләренең беренче җиңүләрен – белем дөньясына ишек ачкан беренче китабын укып чыгуны билгеләп үттеләр. Алар шигырьләр сөйләделәр, җырлар җырладылар, табышмакларга җаваплар таптылар."Әлифба" балаларны укырга гына түгел, ә үзара дус булырга да өйрәткән икән. Укучыларның шатлыкларын уртаклашырга кунаклар да шактый җыелган иде. Әниләренең балаларының уңышлары өчен ихластан шатланып утырдылар. Әлифбадан башланган белемнең нигезе нык, дәвамлы булсын!




Шулай итеп, мәктәпнең иң беренче һәм төп баскычы артта калды. Яңа белемнәр артыннан хәерле юлга, дуслар!

***Закирова Лэйсэн, VIсыйныф укучысы***

*/Безгә кунак килде/*

## *Ветераннар белән очрашу*



Менә февраль ае һәм гражданлык-патриотик тәрбия айлыгы тәмамланды. Бу айда мәктәптә төрле чаралар үткәрелде. Музейга экскурсия, Кыюлык дәресе, «Солдатка хат» акциясе, «Йөрәкләрдә хәтер исән» дип аталган стенгазеталар конкурсы, «Ватаныбыз батырлары» исемле китаплары күргәзмәсе, Советлар Союзы Герое М.Җәлилгә багышланган сыйныф сәгатьләре һәм башка чаралар уздырылды.

Ватанны саклаучылар көне алдыннан районның ветеран оешмасы вәкилләре тарафыннан һәр мәктәптә график буенча "Батырлык дәресләре" уздырыла. Яшь буын белән очрашулар бу оешма эшендә мөһим патриотик юнәлешләрнең берсе булып тора. Безнең укучыларда төрле гаскәрләр флаглары белән хәрби формаларның барлыкка килү тарихы зур кызыксыну уятты. Алар армиядә хезмәт итү, патриотизм һәм погоннардагы кешеләрнең батырлыгы турында сөйләгәннәрен зур игътибар белән тыңладылар. Кызыклы очрашуга җавап итеп, мәктәп укучылары кунакларга патриотик җырлар, әдәби монтажлар, сафка әзерлек үрнәкләре күрсәттеләр.



***Камил Төхфәтуллин, VI сыйныф укучысы***

*/Безнең сәяхәтләр/*

## *Алабугада һөнәр сайлыйбыз*

alabuga POLYTECH алабуга ПОЛИТЕХ

Һөнәри юнәлеш бирү минимумын гамәлгә ашыру кысаларында 17 февральдә 8-11 сыйныф укучылары Аксубай районы мәктәпләреннән тупланган төркем составында Алабуга сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисади зонага (“Алабуга Политех” мәгариф үзәге) бардылар. Укучылар бу уку йортының барлык юнәлешләре һәм аның матди базасы белән таныштылар. “Алабуга Политех” турында презентация карадылар. Аннан соң очрашуда катнашучыларга “Эшлекле мәчеләр” уеннары уздырылды. Безнең укучылардан **Хәйруллин Айназ** белән **Шичкина Карина** шушы уеннар буенча практик эштә уңышлы гына нәтиҗәләргә ирештеләр. Бу бизнес-уенның шарты шундый: укучы бу мәчеләрне уңышлы бәядән сатып җибәрергә тиеш. Әгәр укучы бу эшнең берничә турын да нәтиҗәле итеп эшләсә, димәк ул бу уку йортына укырга керә ала диган сүз. Безнең укучыларга “Алабуга Политех” уку йорты бик нык ошады. Аларга киләчәк һөнәрләрен сайлауда уңышлар телибез.

***Алсу Сафиуллина, XI сыйныф җитәкчесе***

*/Укучылар иҗаты/*

## *Әгәр тылсымчы булсам...*



Их, әгәр дә мин тылсымчы булсам, авыл янына шифалы сулы чишмә булдырыр идем. Бу минем башыма килгән иң беренче теләгем, чөнки авылым кешеләре су алыр өчен ерак чишмәләргә йөрергә мәҗбүр. Ә авылда булса, тирә-ягын матур итеп ясар идек, кешеләр дә мәрхәмәтлерәк булыр иде. Язучылар әйткәнчә, чишмәле авылларның кешеләре шундый була.

Икенче теләгем – өйдә әнием һәрвакыт елмаеп торсын иде. Әни бәхетле булса, гаиләдә барлык кеше дә канәгать була. Әнинең шундый елмаюлары безгә барыбызга да шатлык өсти. Аннан соң бу дөньяда беркем дә авырмасын иде. Сәламәт кешеләр яшәгән җирдә генә тормыш матур була. Туганнарым, якыннарым, авылдашларым барысы да матур яшәрләр иде дим.

Иң зур теләгемнең тагын берсе – дөньялар тынычлансын, сугышлар тәмамлансын иде. Минем бала вакытымны ниндидер шартлаулардан куркып үткәрәсем килми. Тагын бер кечкенә генә теләгем бар да инде, әйтсәм әйтим – минем каникулларны озынайтасым килә. 7 ай укып, 5 ай ял итсәк иде. Алай дисәң, ялның беркайчан да җиткәне юк.

***Васила Залиева, VII сыйныф укучысы.***


Газетаны гамәлгә куючы – Түбән Майна урта мәктәбе
Мөхәррир – Фәнүзә Гафиятуллина
Редколлегия әгъзалары: Зәйнәп Нурматова, Самат Гафиятуллин, Кәүсәр Насыйрова, Ләйсән Закирова, Мәдинә Әхсәнова, Камил Төхвәтуллин



## *Гражданлык-патриотик тәрбия айлыгы*

2 нче февраль көнне бөтен Россиядә Сталинград сугышында совет гаскәрләре тарафыннан герман-фашист гаскәрләрен тар-мар итү көне билгеләп үтелә. Сталинград сугышы (1942-1943) Донның уң ярында башлана, анда 2 миллионнан артык кеше катнаша, ә миллионнан артык кеше һәлак була. Ул Сталинградта иң канлы урам сугышлары һәм өч фронт совет солдатларының гаҗәеп батырлыгы белән билгеләнә. Бу сугыш Бөек Ватан сугышының барышын үзгәртә.Әлеге вакыйга уңаеннан мәктәбебездә Мамай курганындагы "Сталинград сугышы" тыюлыгы музее буенча виртуаль тур уздырылды.



4нче февраль –язучы Михаил Пришвинның туган көне буларак билгеләнеп үтелә. Шул уңайдан башлангыч сыйныф укучылары белән авылыбызның китапханәсенә юл тоттык. Укучылар монда Пришвинның әсәрләрен укыдылар, язучының биографиясе белән таныштылар.



8 февральдә Россия Фәннәр академиясенә нигез салынуга 275 ел тулу уңаеннан “Россия фәне көне” бәйрәмен оештыру турында карар кабул ителде. Быел РФА нигез салынганына 300 ел узды иде. Безнең мәктәптә бу вакыйга хөрмәтенә башлангыч сыйныф укучылары белән сыйныф сәгатьләре үткәрелде, анда аларга Россияда фәннәр тарихы, аларның әһәмияте турында сөйләделәр һәм биремнәр бирделәр.



Гражданлык-патриотик тәрбия айлыгы кысаларында безнең мәктәп укучылары һәм укытучылары, Бөек Ватан сугышы вакыйгаларын тагын бер кат искә алу өчен, музей янына җыелдылар. Тарих укытучысы Рафик Гомәр улы мәктәп музеенда бу сугыш турында җыелган мәгълуматлар турында сөйләде. Аннан соң укучыларга Бөек Ватан сугышында кулланылган сугыш кораллары турында мастер-класс үткәрде. Балаларга мәктәптә булган кораллар күрсәтелде, һәрберсенең җитешсезлекләре һәм уңай яклары турында сөйләнде. Аларны барлыкка китергән кешеләр дә әйтеп үтелде.



15 февральдә, совет гаскәрләрен Әфганстаннан чыгару хөрмәтенә, Россиядә мөһим истәлекле дата – Ватаннан читтә хезмәт бурычын үтәгән россиялеләрне искә алу көне билгеләп үтелә. Истәлекле дата бу вакыйганы искә төшерү өчен һәм Әфган сугышыннан әйләнеп кайтмаган 14 меңнән артык совет солдаты һәм офицерны искә алу хөрмәтенә билгеләнгән. Бу вакыйга уңаеннан безнең мәктәптә укучыларга сыйныф сәгатьләре үткәрелде. Анда укучылар Әфган сугышы турында үз белемнәрен тикшерделәр.



Татар дөньясы мәшһүр улын – герой-шагыйрь Муса Җәлилне туган көне уңаеннан һәр елны 15нче февральдә искә ала. Шул уңайдан мәктәбебездә сыйныфтан тыш чаралар уздырылды. Әлеге чарада укучылар шагыйрьнең биографисе белән таныштылар, шигырьләрен укыдылар һәм тыңладылар. Һәр халыкның үзенең күренекле уллары һәм кызлары бар. Алар турында яшь буын вәкилләре белеп үсәргә тиеш.

***Гөлшат Закирова, башлангыч сыйныф укытучысы.***

## */Котлыйбыз!/*



Февраль аенда дөньяга килгән дусларыбыз **Камалов Илнурны** (III сыйныф), **Донсков Артурны** (Vсыйныф), **Хәбибрахманов Абдулланы** (V сыйныф), **Хасанов Стасны**(VII сыйныф), **Йосыпов Рәсимне** (VIIсыйныф) туган көннәребелән котлыйбыз. Укучыларыбызга сәламәтлек, тырышлык, уңышлар телибез.

Башлангыч сыйныфлар укытучысы **Закирова Гөлшат апаны** да гомер бәйрәме белән котлап, сәламәтлек, озын гомер, уңышлар теләп калабыз!






## *Туган телләр бәйрәме нәтиҗәләре*

21 февральдән башлап ел саен Россиядә тел һәм мәдәни күптөрлелекне яклау максатыннан Халыкара туган тел көне билгеләп үтелә 20 нче февральдә В.Г.Тимирясов исемендәге Аксубайның беренче урта гомуми белем бирү мәктәбендә "День родного русского языка" дип исемләнгән конкурсның шигырьләр номинациясе буенча бәйге булып узды. Конкурста укучылар юбиляр язучыларның шигырьләрен укыдылар. Безнең кызлар да үзләренең осталыкларын күрсәтте. Мин – **Закирова Ләйсән** җиңүче исеменә лаек булдым. IV сыйныф укучысы **Нурматова Асия** 2 нче урынны яулады. Укучыларыбызга олы хезмәтләре өчен рәхмәт әйтеп, алда тагын да зуррак уңышлар теләп калабыз.



Шулай ук татар теле буенча да 21 нче февраль – Туган телләр көнендә бәйрәм уздырылды. Ел сан бу көн бәйрәм төсе алып билгеләп үтелә. Туган телеңә хөрмәт, аны камил белү- һәркемнең бурычы булган кебек, бәйрәмдә катнашу да шул дәрәҗәдә тора. Безнең укучыларыбыз " Нәфис сүз" бәйгесендә уңышлы чыгыш ясадылар. **Вәлиев Ибраһим** белән **Морадимов Илсур** ана теленең сафлыгы, дәрәҗәсе турындагы шигырьләрне сәхнәдә яңгыраттылар. **Насыйрова Кәүсәр** "Күгәрчен гөрлидер" дигән халык




җырын башкарды. VII сыйныф укучысы **Ибраһим** – 2нче, XIсыйныф укучысы **Илсур** – 3нче урыннарны алдылар. Рәсем буенча да VI сыйныфтан **Настя** – 3нче, II сыйныфтан **Руфинә** 2нче урыннарны алдылар. Укчыларыбызга мәктәп даннын һәрвакыт шулай яклап, уңышка ирешүләрен телибез.

Туган тел көне хөрмәтенә мәктәбебездә тагын бер чара үткәрелде. Бу юлы инде ул башлангыч сыйныф укучылары арасында шигырьләр бәйгесе буларак узды.. Укучылар халыкыбызның мәдәниятен һәм телен саклауның әһәмиятен аңлаулары бик мөһим. Шуңа күрә аларга моның турында искә төшереп торырга, сөйләм телләрен баету өчен шундый чаралар уздыру зарури булып тора.

***Ләйсән Закирова, VI сыйныф укучысы***

## *Шахматтагы уңышлар*



23 февраль көнне Аксубай районының "Авыл таңнары" газите редакциясе бинасында газетаның элекке редакторы Фәхертдин Шаязданов истәлегенә шахмат турниры узды. Редакциядә бәйрәм рухы хөкем сөрә иде: шахмат интеллектуальләре, редакторның гаилә әгъзалары, кунаклар барысы да күтәренке кәеф белән килгән. 50 уенчы арасында безнең укучыбыз **Фаил Гафиятуллин** да бар иде. Җиңүчеләр 3 номинациядә билгеләнде. Фаил ир-атлар арасында беренчелекне алып кына калмый, "Иң нәтиҗәле уенчы" исеменә, район башлыгы Камил Камал улы Гилмановның шәхси бүләгенә ия булды. Нәтиҗәдә, 1нче урын өчен термопот, район башлыгы бүләге– манты пешерү кәструле белән бүләкләнә. Фаилгә алдагы бәйгеләрдә дә уңышлар телибез!!!

---

## *Көрәшчеләр ничек ял итә?*



18нче февраль көнне көрәш түгәрәгенең тренеры Камалов Илһам абый безгә кышкы экскурсия оештырды. Бу чараны ел саен көтеп алабыз. Чәчәби тавында шуып, күңел ачып кайтабыз. Юлга иртән үк кузгалдык. Үзебез белән бераз ашарга, чәй алдык. Илһам абый безгә кызырып бирү өчен купаты да әзерләгән иде.

Баргач учак кабыздык. Кемнәрдер тауда шуды. Ашагач “тау патшасы” уенын да уйнадык. Безнең янныбызга Габдуллин Әсхат абый да гаиләсе белән килеп китте. Авылдашлар белән очрашу ялыбызга тагын да бер кызык өстәде. Өйдә телефонда уйнап утыру кебек түгел шул инде мондый көннәр. Рәхәтләнеп күңел ачып, учак янында сөйләшеп, сыйланып кайттык. Илһам абыйга мондый очрашу, хәрәкәтле уеннар оештырганы өчен зур рәхмәтебезне җиткерәбез.

***Самат Гафиятуллин, X сыйныф укучысы***